**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 27 февралендәге 465 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 13 декабрендәге 5162 номерлы**
**«2025 елда Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 9 һәм 40 статьяларын үтәү йөзеннән, Казан шәһәрендә укучыларны белем бирү учреждениеләренә яңадан булдырылган маршрутлар буенча алып бару һәм алып кайтуны оештыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 13 декабрендәге 5162 номерлы «2025 елда Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турында»гы карарына, 3 номерлы кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 26-28 юллар белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

| № | Маршрут номеры | Мәктәп (укучыларның килү урыны) | Торак пункт (укучыларны җибәрү урыны) |
|---|---|---|---|
| «26 | 102 ш | Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 151 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Займище торак массивы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27 | 106 ш | Казан шәһәре Совет районының «185 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Самосырово торак массивы |
| 28 | 108 ш | Казан шәһәре Совет районының «95 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Вознесенское торак массивы» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**